# Низамова Роза Нәгыйм кызы



Низамова Роза Нәгыйм кызы 1947 нче елның 4 августында Татарстан Республикасы Мөслим районы Әмәкәй авылында укытучылар гаиләсендә туа. Сигезьеллык мәктәпне Әмәкәйдә тәмамлый, урта белемне Күбәк мәктәбендә ала. Алабуга культура училищесын китапханәчеләр әзерли торган бүлеген, 1982 нче елда Казан дәүләт мәдәният институтын тәмамлый. Озак еллар Мөслим урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта, мәктәп китапханәчесе эшен алып бара.

Хезмәтен югары бәяләп, район мәгариф бүлегенең һәм ТР мәгариф министрлыгының күпсанлы Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. 2000 нче елда ТР мәгариф министрлыгының “Мәгарифтәге казанышлары өчен” билгесе белән бүләкләнә, ә 2002 нче елда “Татарстан Республикасынын атказанган мәктәп укытучысы” дигән мактаулы исем бирелә.

Роза Нәгыймовна 2002 елдан лаеклы ялга китә, әмма бүген дә бик актив тормыш алып бара, җәмәгать эшләрен башкара. Тынгысыз укытучы район газетасына ветеран укытучылар, кызыклы шәхесләр турында мәкаләләр яза. Россия пенсионерлар союзында член булып тора, район ветераннар советы эшендә катнаша, картиналар чигү буенча мастер- класслар, күргәзмәләр үткәрә. Чигү белән кызыксынып, журналлар, чигү җепләре кайтарта һәм үзлегеннән өйрәнеп, чигү эшенә керешә. Аның чигү –картиналары Мөслим районы үзешчәннәренең смотр –концерты вакытында Камал театрының фойесын бизәсә, Алабуга шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм иткәндә, Мөслим делегациясенең чыгышын тулыландыра. Ул үзенең осталыгын чигү белән кызыксынган һәркемгә өйрәтә. Хәзер инде аның “укучылары” да үзләренең иҗат эшләре белән төрле бәйгеләрдә катнашалар. Укучылар белән еш очраша. Остаз буларак, яшь укытучылар алдында чыгыш ясый, ачык

дәресләр үткәрә,  “Картаймагыз әле ветераннар” клубы эшендә актив катнаша.

Мөслимнең “Матурлык тудыручысы”-Роза Нәгыйм кызы турында язмалар “Ватаным Татарстан”, ”Земля –землица” газеталарында, “Сөембикә” журналында яктыртылды, “Авыл офыклары” телетапшыруында күрсәтелде.

Роза Нәгыймовна сәнгатькә гашыйк зат: җырлый да, бии дә, сәнгатьле итеп  сөйли дә, үзе дә шигырьләр  иҗат итә. Район ветераннар советы каршында оешкан “Сүнмәс дәрт” клубының актив әгъзәсы, клуб оештырган концертларның алыштыргысыз алып баручысы да ул.

Лаеклы ялга чыккач та бик күп диплом, Мактау кәгазьләре белән бүләкләнде: 2015 елда иҗтимагый совет эшчәнлегендә актив катнашканы өчен Мөслим муниципаль район советының Рәхмәт хаты; 2016 ел Татарстан Республикасы ветераннар арасында үткәрелгән “Балкыш” фестивалендә “Нәфис сүз”  номинациясендә катнашып, Диплом белән бүләкләнде; 2017 ел Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Рәхмәт хаты; 2018 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим районы мәгариф идарәсенең Рәхмәт хаты, 2019 нче елда Мөслим муниципаль районы иҗтимагый советы Рәхмәт хаты, ТР Мөслим районының мактау грамотасы белән.

Бүгенге көндә  китапханә советында һәм “Ак калфак” хатын-кызлар оешмасы әгъзасы.

2020 нче елда Татарстан АССР төзелүгә 100 ел тулуга багышланган билге белән бүләкләнә.

Тормыш иптәше Илгиз Низамов лаеклы ялда. Ике кызлары югары белем алып, үз һөнәрләре буенча эшлиләр. Ике онык тәрбиялиләр